Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 30 апреле 51№

Әлки муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында»гы 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль-хосусый партнерлык кысаларында җирле үзидарә органнарының, юридик затларның үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы, 2005 елның 21 июлендәге "Концессия килешүләре турында" 115-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 13 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 224-ФЗ Федераль закон, 2020 елның 29 декабрендәге «Алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 464-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә (2018.17.12, 206№ ред.) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7 бүлекнең 2 абзацында түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә: "14)алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешма объектлары.".

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин